**ГЛАВА НОВОИГЛАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Яңа Иглай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын Якты Күл мәдәният йортында 2019 елның 2 декабрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын Якты Күл мәдәният йортында 2019 елның 2 декабрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында Елга урамы буенча 24 нче йорт янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2019 елның 3 декабрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Якты Күл авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Якты Күл авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Ф.С. Гайнуллин